ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«13» май 2019 года

КАРАР
№ 18

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча
административ регламентлар раслау

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Минстрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Минстрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2 ноябрь 2010 елның 880 нче карарына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципал хезмәтләр” 2019 ел 19 апрель 167 карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнакавыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Расларга:

1.1.Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (1 нче кушымта);

1.2. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнәмәсе буенча бирелә торган торак урыннарын алыштыру буенча документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3. Гражданга социаль наем шартнәмәсе буенча муниципаль милектә булган торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4. Адресларны бирү, үзгәртә 1әм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (4 нче кушымта);

1.5. Документларның кучермәләре һәм алардан өземтәләр тугрылык таныклавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6. Нотариаль гамәлләр башкару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты:васыять 1әм ышаныч таныклыгы (6 нче кушымта);

1.7. Мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрү һәм кирәк булган очракта аларга идарә итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (7 нче кушымта);

1.8.Документларда имзаларның чынлыгын таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (8 нче кушымта);

1.9. Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (9 нче кушымта);

1.10. Агач, куаклар кисүгә һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (10 нче кушымта);
1.11. Муниципаль милектә булган җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (11 нче кушымта);
1.12. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (12 нче кушымта);

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнакавыл җирлеге башкарма комитетының “Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентлар раслау турында” 2013 елның 29 апрелендәге №9 карарын (20.12.2013 ел №17; 25.09.2015 ел №13; 14.10.2015 ел №15№16,№17,№18,№19 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмәт рәсми порталы” интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә ( baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Борнакавыл җирлеге башлыгы Ш.М.Хәбибуллин